СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.08.2019 п.г.т. Алексеевское № 209

**«Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Алексеевск шәһәр җирлеге бюджетыннан
юридик затларга (дәүләт муниципаль
субсидияләреннән кала), шәхси эшмәкәрләргә,
физик затларга – товар җитештерүчеләр,
эшләр һәм хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр
бирү турында Нигезләмәне раслау турында”
Алексеевск муниципаль районы
Алексеевск шәһәр җирлеге Советының
4 апрель, 2014 ел, 858 нче карарына үзгәрешләр кертү
турында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Физик затларга – товар җитештерүчеләр, эшләр һәм хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокук актларына, муниципаль хокук актларына гомуми таләпләр турында” 6 сентябрь, 2016 ел, 887 нче Хөкүмәте карарына туры килмәүне бетерү, Алексеевск муниципаль районы прокуратурасының 24 июнь, 2019 ел, 02-01-16-2019 нче таләбен үтәү йөзеннән

**Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карар бирде:**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге бюджетыннан юридик затларга дәүләт (муниципаль) учреждени-еләренә, индивидуаль эшмәкәрләргә, физик затларга - товар җитештерүчеләргә, эшләр һәм хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр бирү турында Алексеевск Сове-тының 2014 елның 4 апрелендәге 858 номерлы карары белән расланган Татар-стан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге бюджетыннан түбәндәге эчтәлекле нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

1.1 нче пунктның 5 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5) финанс тәэминаты чыганагы күрсәтелгән субсидияләр булган субсидия алучының акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә

бирелгән субсидияләрдән тыш, хисап финанс елында товарлар җитештерү (гамәлгә ашыру), эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында бирелгән субсидияләр калдыкларын кире кайтару очраклары һәм тәртибе (финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы-күрсәтелгән субсидияләр));»

2.55 нче пунктның 1 нче абзацның түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.Субсидия алу хокукына ия булган юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм физик затларга түбәндәге очракта субсидияләр бирүдән баш тартыла:»

2. Әлеге карарны Алексеевск шәһәр җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Алексеевск шәһәр җирлеге**
**башлыгы,Совет рәисе** **С.А. Демидов**